**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422645С.Большой Салтан,
ул. Р.Шарафеева, дом 59

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
***БАШЛЫГЫ***

422645, Олы Солтан авылы,
Р.Шәрәфи урамы, 59 нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 11 ноябре Олы Солтан авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Олы Солтан авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законы , Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Солтан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Олы Солтан авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 26 ноябренә сәг. 10.00гә билгеләргә.
2. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Олы Солтан авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 1 группа инвалидлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Солтан авылында Р.Шәрәфеев урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны төзекләндерүгә (вакланган таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эш барышы өчен түләү);

- кышкы чорда авыл җирлегенә керүче торак пунктлардагы юлларны карап торуга:

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча

урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

СОВЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ